Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-9**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәгемуниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) хокукларыннан бәйсез булганһәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнештәге муниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибен һәм шартларын раслау турында

Аренда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү шартларында муниципаль милектән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү максатларында, 2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 маддәсенең 4.1 өлешенә, 2018 елның 3 июлендәге “Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне көчәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 185-ФЗ номерлы Федераль законга, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе 1 өлешенең 25 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәгемуниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) хокукларыннан бәйсез булганһәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен

билгеләнештәгемуниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибен һәм шартларын расларга (теркәлә).

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 16 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге өченче затларның хокукларыннан бәйсез (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнештәге мөлкәт исемлеген төзү, аны алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибе, күрсәтелгән муниципаль мөлкәтне (җир кишәрлекләреннән гайре) арендага бирү тәртибе һәм шартлары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе хакындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2006 елның 2 декабрендәге XI-4 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында”гы XIII-11 номерлы карарының 1 һәм 2 пунктларын көчен югалткан дип танырга .

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның
4 сентябрендәгеXXXIII-9номерлы
карары беләнрасланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) хокукларыннан бәйсез булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнештәге муниципаль мөлкәтне арендага бирү**

**Тәртибе һәм шартлары**

I.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип һәм шартлар Россия Федерациясенең Гражданнар кодексына, Россия Федерациясенең Җир кодексы,2003 елның 6 октябрендәге“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законга, 2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы Федераль законга, 2006 елның 26 июлендәге “Конкуренцияне яклау турында”гы 135-ФЗ номерлы законга, Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль хокукый актларына туры китереп эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәгемуниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгәнмуниципаль мөлкәтне , шул исәптән җир кишәрлекләрен дә( шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, яшелчә, җиләк-җимеш үстерү бакчачылыклары, ялгыз торак төзелеше өчен билгеләнештәге җир кишәрлекләреннән гайре),йортлар, каралты-куралар, корылмалар, торак булмаган биналар, җиһазлар, машиналар, механизмнар, җайланмалар, кораллар, транспорт чаралары, инвентарьларны,өченче затларның хокукларыннан бәйсез (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнештәге мөлкәтне (алга таба – тиңдәшле рәвештә мөлкәт, исемлек) арендага бирү механизмын билгелиләр.

1.2.Исемлеккә кертелгән мөлкәтнең милек иясе – Татарстан Республикасының “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге.

1.3.Исемлекне төзү, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару (халыкка игълан итү)Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль район Советы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының муниципаль хокукый актлары тарафыннан билгеләнә.

1.4.Муниципаль мөлкәтне арендага бирүче булып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тора.

1.5.Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендага алучы булып кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче (2007 елның 24 июлендәге "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында"гы 209-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендә күрсәтелгән эшчәнлекләрен дәүләт учреждениеләре формасында гамәлгә ашыручы фәнни, фәнни-техник, инновация эшчәнлегенә ярдәм итүче дәүләт фондларыннан гайре) оешмалар торырга мөмкин.

## II. Муниципаль мөлкәтне арендага бирү

2.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзү исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион формасындагы ачык торги (алга таба – торги) нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

2.2.Арендага бирүче торгины оештыру һәм үткәрү функцияләрен гамәлгә ашыра. Арендага бирүче торгины оештыру һәм үткәрү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен шартнамә нигезендә юридик затны (махсуслашкан оешманы) җәлеп итәргә хаклы.

2.3.Торгины үткәрү тәртибе, торги нәтиҗәләре буенча исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү Россия Федерациясе Җир кодексы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2010елның 10 февралендәге "Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышаныч нигезендә идарә итү шартнамәләрен, дәүләти яки муниципаль мөлкәткә карата хокук күчүне күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе һәм аңа карата күрсәтелгән шартнамәләрне төзү конкурс формасында торги үткәрү юлы белән мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге турында"гы 67 номерлы Боерыгы белән расланган аренда шартнамәләрен,түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышаныч нигезендә идарә итү шартнамәләрен, дәүләти яки муниципаль мөлкәткә карата хокук күчүне күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү Кагыйдәләре(алга таба – Кагыйдәләр) тарафыннан билгеләнә.

2.4.Исемлеккә кертелгән мөлкәткә карата төзелә торган шартнамәләрнең срогы биш елдан да ким булырга тиеш түгел. Шартнамә срогы мөлкәткә ия булу һәм (яки) аннан файдалану хокукын алучы затның шартнамәне төзегәнгә чаклы бирелгән гаризасы нигезендә киметелергә мөмкин.

2.5.Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне арендага алучы аннан файдалану хокукын башкага бирергә, аннан файдалану хокукын залог итеп бирергә һәм мондый мөлкәт белән файдалану хокукын хуҗалык эшчәнлегенең теләсә кайсы башка субъектларының устав капиталына кертергә, мондый мөлкәтнең аренда шартнамәләре буенча хокук һәм йөкләмәләрен өченче затларга тапшырырга (перенаем), субарендага тапшырырга ( мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирүдән гайре) хакы юк, әгәр субарендага 2006 елның 26 июлендәге "Конкуренцияне яклау турында"гы135-ФЗ

номерлыФедераль законның 17.1 маддәсенең 1 өлеше 14 пунктында күздә тотылган мөлкәт бирелү очрагы булса, аңа да хокуклы түгел.

2.6.Арендага алучы муниципаль мөлкәтне максатчан билгеләнеш буенча 2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тыюларны үтәү шартлары белән файдаланырга тиеш.

## III.Аренда түләве һәм аны кертү тәртибе

3.1.Мөлкәтне арендалау шартнамәсендә аренда түләвенең күләме Россия Федерациясе Җир кодексында, Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә торгины үткәрү процессындабилгеләнә. Аренда түләвенең башлангыч күләме (торги предметының башлангыч бәясе) Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеген җайга салучы гамәлдәге законнар нигезендә үткәрелүче аренда түләвенең базар хакын бәяләү нигезендә билгеләнә.

3.2.Аренда түләвенең күләме коммуналь хезмәтләр өчен түләү, техник хезмәт күрсәтү, арендага тапшырылган мөлкәтне саклау чыгымнарын һәм бирелгән мөлкәтне тоту һәм куллануга бәйле килеп туган башка чыгымнарны , шулай ук мөлкәтне мәҗбүри иминиятләштерүгә чыгымнарны үз эченә алмый.

3.3. Мөлкәтне арендалаучы һәм эшчәнлекнең социаль әһәмияткә ия төрләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты ның 2016 елның 11 августындагы 123пи номерлы карары белән расланган “2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программасында билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәтнең аренда түләве буенча ташлама бирелә.

Күрсәтелгән ташлама түбәндәге күләмнәрдә аренда түләвен билгеләүдән гыйбарәт:

арендаprovíның беренче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән бер елга аренда түләвенең 20% ы;

арендаңың икенче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән бер елга аренда түләвенең 40% ы;

арендаңың өченче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән бер елга аренда түләвенең 60% ы;

арендаңың дүртенче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән бер елга аренда түләвенең 80% ы;

арендаңың бишенче елында һәм алга таба – аренда шартнамәсендә билгеләнгән бер елга аренда түләвенең 100% ы.

3.4.Эшчәнлекнең социаль әһәмияткә ия төрләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 11 августындагы 123пи номерлы карары белән расланган “2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программасында билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле башка төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелгән мөлкәткә карата төзелгән (арендатор әлеге Тәртипнең

3.3пунктында күздә тотылган критерийларга туры килми башлаган очракта, аның аренда шартнамәсе буенча йөкләмәләрен үтәмәве сәбәпле) аренда шартнамәсе вакытыннан элек өзелгәндә, муниципаль мөлкәт белән фактта файдаланган бөтен срок аны төзү хокукы өчен үткәрелгән торги нәтиҗәләре буенча төзелгән шартнамәдә билгеләнгән аренда хакыннан 100% күләмдә түләнергә тиеш.

3.5.Исемлеккә кертелгән мөлкәтне яңа срокка арендалау шартнамәсе төзегәндә арендатор тарафыннан аренда түләве аны төзү хокукы өчен үткәрелгән торги нәтиҗәләре буенча төзелгән шартнамәдә билгеләнгән аренда хакының 100% ы күләмендә кертелә.

3.6.Муниципаль мөлкәтне файдаланган өчен аренда түләве Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыбюджетына күчерелә.